**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Учаллинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 51, село Учалле,
Азнакаевского муниципального района, 423317

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авылы**
**җирлеге башкарма комитеты**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы
423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2019 ел №28

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитете 30.01.2019 ел №2 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнец административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенец аерым закон актларына территорияне планлаштыру, территорияләрне комплексцы һәм тотрыклы үстерүне тәэмин итү буенча документларны әзерләүне, килештерү һәм раслау өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларыныц аерым нигезләмәләренец үз көчләрен югалтуын тану турында» 03.07.2016 ел № 373-ФЗ Федераль Закон нигезендә,

Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитете 30.01.2019 ел №2 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнец административ регламентлары турында» карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнец административ регламентына, 1.5 пунктыныц унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«планлаштыру структурасыныц элементы-җирлек территориясенец бер өлеше (квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларыныц төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина